| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОРЫНДЫК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 октябрь 2019 ел Борындык авылы № 11

2019-2029 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында

2016 елның 27 июлендә Россия Федерациясе Транспорт һәм юл хуҗалыгы министры М.Ю.Соколов Россия Федерациясе субъектлары җитәкчеләре белән транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшләүгә һәм раслауга кагылышлы мәсьәләләр буенча уздырган 58 нче селектор киңәшмәсе беркетмәсенең II бүлеге 2 нче пунктындагы транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә норматив хокукый актларны гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча муниципаль берәмлекләр өчен транспорт инфраструктурасын комплексы үстерү программаларын эшләүгә һәм раслауга кагылышлы өлеше, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 19 декабрендәге 03-16/5899 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегендә транспорт инфраструктурасын үстерүне тәэмин итү, аның иминлеге дәрәҗәсен күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1. “2019-2029 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге транспорт инфраструктурасын комплексла үстерү программасын” расларга (кушымта).
2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 22.июнендәге 10 номерлы «2016-2030 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге транспорт инфраструктурасын комплексла үстерү программасын раслау турында» карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Борындык авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.Р.Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның «07» октябрендәге 11 номерлы карарына кушымта

# 2019- 2029 ЕЛЛАРГА
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОРЫНДЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН КОМПЛЕКСЛЫ ҮСТЕРҮ
# ПРОГРАММАСЫ

Борындык авылы
2019 ЕЛ
1. ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Программа исеме | 2019-2029 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы |
| 2. | Программаның заказчысы, әзерләүче һәм башкаручысы | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 3. | Программаны әзерләү өчен нигез | - 2014 елның 29декабрендәге 456-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы;<br>-Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы «Җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» карары;<br>- Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2016 елның 06 июнендәге 326661-МР номерлы «Муниципаль берәмлекләрнең транспорт инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программасын эшләү турында» күрсәтмәсе. |
| 4. | Программаның максаты һәм бурычлары | Максат: Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегендә транспорт инфраструктурасын үстерүне, аның иминлеген арттыруны тәэмин итү.<br>бурычлар:<br>- транспорт инфраструктурасы объектларын төзүне, реконструкцияләүне тәэмин итү;<br>-муниципаль берәмлек территориясендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру |
| 5. | Транспорт инфраструктурасын үстерүнең максатчан | - гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәткечләре (индикаторлары) | озынлыгы;<br>- транспорт инфраструктурасы объектларын төзү , реконструкцияләү проектлары саны;<br>- төзелгән, реконструкцияләнгән автомобиль юлларының озынлыгы;<br>-юл хәрәкәтен оештыруның гамәлгә кертелгән техник чаралары саны. |
| 6. | Программаны гамәлгә кую сроклары | 2019-2029еллар |
| 7. | Программа чаралары | «Транспорт комплексын үстерү өстенлекләре» 5 бүлегендә китерелде |
| 8. | Финанслау чыганаклары | ТР бюджеты, МБ бюджеты, бюджеттан тыш чаралар |
| 9. | Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре | - муниципаль берәмлек территориясендә транспорт инфраструктурасын үстерү өчен шартлар тудыру;<br>- муниципаль берәмлек территориясендә юл хәрәкәтендә катнашучыларның якланганлык дәрәҗәсен күтәрү |

## 2.ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР

Авыл җирлегенә 2 торак пункт - Борындык авылы, Шүширмә авылы керә. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге районның көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан: көньяк-көнчыгышта Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге җирләре белән; төньякта Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы җирләре белән; көнбатышта Татарстан Республикасы Яшел Яшел муниципаль районы җирләре белән; көньякта Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге җирләре белән чикләшә.

Административ үзәк Борындык авылы Казан шәһәреннән 80 км ераклыкта, район үзәге Олы Кайбыч авылына кадәр 25 км ераклыкта урнашкан.

Иваново волосте Теньков кантонының Борындык Советының Башкарма комитеты 1918 елда оештырыла. 1924 елда Иваново волосте юкка чыга, Борындык авыл Советы Зөя кантонының Кошман волостена керә. 1927 елда Борындык авыл Советы ТАССРның Кайбыч районы составына керә.

Башкарма комитет халык арасында ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчелегенә һәм дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар уздыру, , халык арасында дәүләт заемына язылу, башка акча җыюлар белән шөгыльләнә. 1931 ел башында Борындык авылында күмәк хуҗалык оештырыла башлый, 1931елның 14нче апрелендә «Фрунзе» колхозы оештырыла. 1944 елда «Фрунзе» колхозы бүленә, «Үрнәк» колхозы оештырыла. 1954 елда Борындык авыл Советы Шүширмә авыл Советы белән берләшә һәм Борындык авыл Советы дип атала. 1957 елда «Фрунзе» колхозы Шүширмә авылының «Көрәшче» колхозы белән берләшә.

1963 елда исемен Куйбышев исемендәге колхоз исеменә алыштыра. 1962 елда, районнарның административ-территориаль бүленешенә бәйле рәвештә, Борындык авыл Советы Буа районы составына керә. 1964 елның октябреннән Борындык авыл Советы ТАССРның Буа районыннан аерыла һәм ТАССРның Апас районы составына керә. 1977 елда СССРның яңа Конституциясе кабул ителгәннән соң Борындык авыл Советы хезмәт ияләре депутатларының Борындык авыл Советы дип атала башлый. 1991 елның апрелендә Апас районы таратыла һәм яңадан Кайбыч районы төзелә, Борындык авыл Халык депутатлары Советы анда керә. Халык депутатларының Кайбыч район Советы Президиумының 1995 елның 07 июлендәге 31 нче карары белән Борындык авыл Советы дип атала башлый. 2005 елның 12 октябреннән башлап, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге дип атала башлады.

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә «Борындык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге төзелә, ул «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керә. Борындык авыл җирлегенең административ үзәге - Борындык авылы.

Авыл җирлегенең административ үзәге Борындык авылы - җирле хуҗалык активлыгы үзәге. Җирлек эчендәге торак пунктлар арасындагы бәйләнеш һәм аның чиген узу автомобиль транспорт төре тарафыннан башкарыла.

Җирле әһәмияттәге юлларның гомуми озынлыгы - 14,7 км.

## 3. ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ.

Җирлек территориясендә тышкы транспорт бер төр - автомобиль транспортыннан гыйбарәт. Борындык авыл җирлегенең торак пунктларында тышкы транспортның күләме зур түгел. Тышкы транспорт җирлекнең район һәм республика үзәкләре һәм күрше муниципаль берәмлекләр белән аралашуы ягыннан зур әһәмияткә ия.

Борындык авылы - авыл җирлегенең административ үзәге, җирле хуҗалык активлыгы үзәге. Җирлек эчендәге торак пунктлар арасындагы бәйләнеш һәм аның чиген узу автомобиль транспорты тарафыннан башкарыла.

Әлеге Программаны гамәлгә ашыру кысаларында Борындык авыл җирлеге үсешенең стратегик өстенлекләре, генераль план, социаль инфраструктураны саклап калуның һәм үстерүнең төп юнәлешләре нигезендә үткәрелгән чаралар мониторингы гамәлгә ашырылачак һәм шуның нигезендә Программа чараларына төзәтмәләр кертеләчәк.

Программаның тышкы транспортны үстерү өлешендә чаралары түбәндәгеләр:

1. Борындык авыл җирлеген территориаль планлаштыруда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын норматив хәлгә кадәр (бөтен чор) китерү чараларын исәпкә алу.

2. Муниципаль берәмлек чикләрендә федераль һәм региональ әһәмияттәге автомобиль юлларын үстерү өчен җир кишәрлекләрен бүлеп бирүгә ярдәм күрсәтү (бөтен чор).

3. Федераль һәм региональ әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларыннан һәм саклау зоналарыннан файдалану режимын үтәүне тәэмин итү (бөтен чор).

Җәмәгать транспорты.

Транспорт - халыкны һәркем файдалана алырлык транспорт белән тәэмин итүче җитештерүчеләр һәм кулланучылар арасында продукциянең төрле төрләрен күчерә торган икътисадның һәм халыкның йөк ташуга ихтыяҗларын канәгатьләндерә торган җирлек инфраструктурасының мөһим состав өлеше. Транспортның тотрыклы һәм нәтиҗәле эшләве җирлекнең барлык предприятиеләрен ташуга һәм уңышлы эшләүгә халыкның ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү өчен кирәкле шарт булып тора. Җирлектә пассажир транспортының төп һәм бердәнбер төре - такси һәм шәхси автотранспорт. Авыл җирлеге территориясендә Казан шәһәре – Олы Кайбыч авылы автотранспорт маршруты уза. Борындык авыл җирлеге территориясендә автотранспорт предприятиеләре юк. Җирлектә хәрәкәт итүләрнең күбесе шәхси автотранспортка һәм җәяүлеләр юлларына туры килә.

## 4. УРАМ-ЮЛ ЧЕЛТӘРЕ

Урам-юл челтәре торак пунктларның транспорт, инженерлык һәм социаль инфраструктурасының төп барлыкка китерүче элементы булып тора. Җирлекнең комплекслы үсешендә юллар челтәрен һәм инфраструктура объектларын үстерү иң социаль әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып тора. Борындык авыл җирлегенең урам-юл челтәренең озынлыгы 14 700 метр тәшкил итә. Җирлектә автомобиль юлларының шактый өлешенә вак таш түшәлгән.

Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлегенең урам-юл челтәре үзенчәлеге 1нче таблицада күрсәтелгән.

1нче таблица

| № п/п | автомобиль юлы исеме | озынлыгы, км | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барысы | Шул исәптән | | | |
| | | | ц/б | а/б | Вак таш | грунт |
| | **Борындык авылы** | | | | | |
| 1 | Яшьләр ур. | 0,3 | | | 0,3 | |
| 2 | Октябрь ур. | 0,5 | | | 0,5 | |
| 3 | Совет ур. | 0,25 | | | 0,25 | |
| 4 | Кутузов ур. | 0,85 | | | 0,2 | 0,65 |
| 5 | Чапаев ур. | 0,3 | | | 0,3 | |
| 6 | З.Абрар ур. | 0,18 | | | 0,18 | |
| 7 | Куйбышев ур. | 0,61 | | | 0,61 | |
| 8 | М .Рамил ур. | 0,76 | | | 0,76 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 9 | М.Гафури ур. | 0,37 | | | 0,37 | |
| 10 | М.Җәлил ур. | 0,25 | | | | 0,25 |
| 11 | Карл Маркс ур. | 0,55 | | | 0,3 | 0,25 |
| 12 | Җиңү ур. | 0,27 | | | 0,27 | |
| 13 | Гадел Кутуй ур. | 0,17 | | | 0,17 | |
| 14 | Ленин ур. | 1,04 | | | 1,04 | |
| | **Шүширмә авылы** | | | | | |
| 1 | Гагарин ур. | 0,45 | | 0,45 | | |
| 2 | Вахитов ур. | 0,79 | | 0,57 | | 0,22 |
| 3 | Кооператив ур. | 0,43 | | | 0,43 | |
| 4 | Габдулла Тукай ур. | 0,97 | | | 0,97 | |
| 5 | М.Гафури ур. | 0,32 | | | | 0,32 |
| 6 | Ямашев ур. | 0,48 | | | 0,48 | |
| | **БАРЫСЫ** | **9,84** | **0** | **1,02** | **7,13** | **1,69** |

## 5. ТРАНСПОРТ КОМПЛЕКСЫН ҮСТЕРҮ ӨСТЕНЛЕКЛӘРЕ

Муниципаль берәмлек транспорт комплексын үстерүнең төп өстенлекләре булып беренче чиратта (2029 ел) торырга тиеш:

- гамәлдәге урам-юл челтәрен ремонтлау һәм реконструкцияләү.

Борындык авыл җирлеге территориясендә транспортны үстерү хакимиятнең төрле баскычлары: федераль, төбәк, муниципаль уртак тырышлыкларына юнәлдерелгән комплекслы якын килү нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш. Авыл җирлегенең транспорт системасын үстерүне планлаштырганда районның һәм тулаем регионның транспорт системасын перспективалы үстерүне исәпкә алырга кирәк. Авыл җирлегенең транспорт системасы регионның транспорт системасы элементы булып тора, шуңа күрә территориядә транспорт инфраструктурасын оптимальләштерүгә бәйле барлык бурычларны хәл итү бары тик җирле үзидарә органнары вәкаләтләре кысаларында гына хәл ителә алмый. Транспорт инфраструктурасын үстерү буенча әлеге Программада барлык дәрәҗәдәге бюджетлар катнашында гамәлгә ашыру күздә тотыла. Борындык авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары бурычлары булып дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча оештыру чаралары, транспорт инфраструктурасын үстерү буенча инициативалы тәкъдимнәр әзерләү тора. Транспорт инфраструктурасын үстерүнең төп юнәлешләре федераль дәрәҗәдә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008елның 22 норябрендәге 1734-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Россия Федерациясе транспорт стратегиясе белән билгеләнде. Транспорт стратегиясе нигезендә транспорт системасын үстерүнең стратегик максаты - икътисадның һәм җәмгыятьнең конкуренциягә сәләтле сыйфатлы транспорт хезмәтләрендә инновацион социаль юнәлешле үсеш ихтыяҗларын канәгатьләндерү.

Нәтиҗәле конкурентлыкка сәләтле транспорт системасын булдыру өчен 3 төп өлеш кирәк:

- конкурентлыкка сәләтле югары сыйфатлы транспорт хезмәтләре;
- югары җитештерүчәнлекле имин транспорт инфраструктурасы һәм аларны конкуренциягә сәләтле югары сыйфатлы транспорт хезмәтләре белән тәэмин итәрлек дәрәҗәдә кирәкле транспорт чаралары;

-транспорт хезмәтләренең тәкъдимнәр дәрәҗәсен ихтыяҗдан арттыру өчен шартлар тудыру (югыйсә көндәшлек мохите булмаячак).

## 6. УРАМ-ЮЛ ЧЕЛТӘРЕН ОПТИМАЛЬЛӘШТЕРҮ

Борындык авыл җирлегенең транспорт комплексы үсешендәге югарыда күрсәтелгән өстенлекләргә ярашлы рәвештә, Программа тарафыннан урам-юл челтәрен оптимальләштерү буенча түбәндә тасвирланган чаралар каралган.

Программа белән нормативлар нигезендә магистраль урам-юл челтәрен формалаштыру буенча тәкъдимнәр бирелә. Авыл торак пункты һәм авыл җирлеге чикләрендә урам челтәренең төп исәп-хисап параметрлары СП 42.13330.2011 “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» нигезендә кабул ителә.

При проектировании улиц и дорог в районах нового жилищного строительства необходимо соблюдать проектную ширину улиц в красных линиях, что позволит избежать в дальнейшем реализации дорогостоящих мероприятий по изъятию земельных участков и сноса объектов капитального строительства с целью расширения улиц. Проектируемые улицы должны размещаться таким образом на рельефе, чтобы было выполнено требование соблюдения нормативных уклонов. Необходимо уделять особое внимание проектированию и строительству основных улиц в условиях наличия сложных геоморфологических факторов.

## 7.ТУКТАУ ҺӘМ ТРАНСПОРТНЫ ОЗАК ВАКЫТКА САКЛАУ УРЫННАРЫН ОЕШТЫРУ.

Җирлек территориясендә автотранспортны саклау, нигездә, предприятиеләр участоклары чикләрендә һәм җирлектә яшәүчеләрнең йорт участокларында, зур булмаган гараж кооперативларында гамәлгә ашырыла. Алга таба, халыкны автомобильләштерү дәрәҗәсе арту фаразын исәпкә алып, җәмәгать билгеләнешендәге биналар янында автомобильләр кую урыннарын оештыруны күз алдында тотарга кирәк. Халыкның җиңел автомобильләрен даими һәм вакытлыча саклау йорт янындагы кишәрлекләр чикләрендә күздә тотыла.

Әлеге бүлек буенча башкарылырга тиешле чаралар:

1. Төзелеш өчен бирелә торган участокларда җәмәгать билгеләнешендәге биналарның проект сыйдырышлылыгы нигезендә кирәкле санда парковка урыннары урнаштыруның административ чаралары белән тәэмин итү(бөтен чор):

2. Хезмәт күрсәтү объектлары янында автостоянкалар төзү (бөтен чор);

3. Иң зур җыелу урыннарында җәмәгать тукталышларын оештыру (беренче чиратта - хисап срогы).

## 8. ҖӘЯҮЛЕЛӘР УРАМНАРЫ ҺӘМ ВЕЛОСИПЕД ЮЛЛАРЫ СИСТЕМАСЫ ТӨЗҮ: МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ ЧИКЛӘНГӘН ЗАТЛАРНЫ КИРТӘЛӘРСЕЗ МӨХИТ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ.

Экологик чиста мохитне саклау өчен, корреспонденция өчен зур булмаган кисемтәләр булганда, торак пунктлар территориясендә Программада җәяүлеләр

өчен урамнар системасы каралган. Җирлек программасы буенча халыкның аз хәрәкәтле төркемнәре өчен киртәләрсез мохит булдыру каралган. Шул максат белән иҗтимагый биналарны проектлаганда киртәләрсез мохит тудыруга кертелгән барлык таләпләр һәм тротуарларның норматив тайпылышлары булган пандуслар урнаштыру буенча таләпләр куелырга тиеш.

Әлеге бүлек буенча чаралар:

1. Җәяүлеләр күпчелек йөри торган урамнар системасын формалаштыру (хисап срогы - перспектива);

2. Төзүчеләр тарафыннан киртәләрсез төзү таләпләрен үтәүнең административ чаралары белән тәэмин итү(бөтен чор).

## ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ

2нче таблица

| Чара исеме | Объектның урнашу урыны | Тормышка ашыру сроклары |
|---|---|---|
| Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының техник документация-сендә булган белешмәләрне актуаль-ләштерү бүленгән полосаларны билгеләү | Борындык ав.<br>Шүширмә ав. | 2019-2029еллар |
| Автомобиль юлларында һәм җирлек урамнарында барлык инженерлык корылмаларының техник торышын бәяләү белән инвентарьлаштыру | Борындык ав.<br>Шүширмә ав. | 2019-2029еллар |
| Юлларның каплануы үзгәрүне исәпкә алып, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының расланган исемлегенә үзгәрешләр кертү | Борындык ав.<br>Шүширмә ав. | 2019-2029еллар |
| Территорияләрне планлаштыру документларын эшләү белән комплекста хәл ителә торган юл хәрәкәте иминлеге буенча чаралар комплексын эшләү һәм гамәлгә ашыру | Борындык ав.<br>Шүширмә ав. | 2019-2029еллар |
| тукталыш мәйданчыклары җиһазы һәм җәмәгать транспорты өчен павильоннар урнаштыру | Борындык ав.<br>Шүширмә ав. | 2019-2029еллар |
| Торак һәм сәнәгать төзелеше өчен яңа территорияләр үзләштергәндә юлларны һәм тротуарларны комплекслы төзү | Борындык ав.<br>Шүширмә ав. | 2019-2029еллар |
| Торак пунктлар урамнарында каты өслек урнаштыру реконструкцияләү, ремонтлау | Борындык ав.<br>Шүширмә ав. | 2019-2029еллар |